МЭР
ГОРОДА БАВЛЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2019 Баулы шәһәре № 34

Баулы шәһәр Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28нче статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Баулы шәһәр Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2019 елның 20 ноябренә сәгать 10:00, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20нче йорт, утырышлар залы адресы буенча билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы итеп Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасын билгеләргә.

3. Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Л.С. Свежинкинага түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү буенча законнар, муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне;

- кызыксынган затларга ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирүне;

- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне вакытында әзерләү һәм бастырып чыгаруны.

4. Фикер алышу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20нче йорт., 114нче каб. адресы буенча кабул ителә (эш көннәрендә 9:00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр, тел. 6 07 11).

5. Кушымта нигезендә, керә торган тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

6. Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проектын http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://bavly.tatar.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы шәһәре Мэры — БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ / БАУЛЫ ШӘҺӘР СОВЕТЫ — Р.Х. Гатиятуллин

Баулы шәһәре Мэрының  2019 елның
« 10 » 10 кабул ителгән
34 карарына кушымта

Керә торган тәкъдимнәрне
исәпкә алу, гомумиләштерү
һәм карау буенча эшче төркем
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Бакиров<br>Данияр Ленар улы | - | «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе - эшче төркем җитәкчесе; |
| Ветчинова<br>Людмила Ивановна | - | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 17нче номерлы районара инспекциясе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча); |
| Свежинкина<br>Лилия Салихяновна | - | Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе; |
| Тимофеев<br>Станислав Николаевич | - | Баулы шәһәр Советы депутаты, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Баулы шәһәре, Баулы һәм Ютазы районнары буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Хрисанова<br>Лариса Сергеевна | - | Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе урынбасары. |